Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге
Юныс торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

16 октябрь, 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлегенең Юныс торак пунктында 2024 елның 16 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 36 (утыз алты).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 19 (унтугыз).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 19 (унтугыз)
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2025 елда Юныс торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пимәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов